ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Ташкичү авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча фикер алышу ачык тыңлауларының
**7 номерлы беркетмәсе**

**Рәсмиләштерү датасы:** 09.12.2025

**Рәсмиләштерү урыны:** 422000, Татарстан Республикасы, Арча районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12 йорт

**Ачык тыңлаулар** Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының **2025 елның 31 октябрендәге 01-09-25455 номерлы** карары белән оештырылды, алар Арча муниципаль районы башлыгының 2025 елның 17 ноябрендәге 180 номерлы “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар уздыруны билгеләү турында” карары белән билгеләнде, чыгарылды:

- Арча муниципаль районының рәсми сайтында: (https://arsk.tatarstan.ru) 17.11.2025;
- Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) 17.11.2025.

Гавами тыңлауларны оештыручылар:

1) Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Р.Р.Филиппова;

2) Юридик мәсьәләләр буенча бүлек башлыгы — Л.Г.Сәгыйтова;

3) Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы — И.М.Хәсәнов;

4) “Ташкичү авыл җирлеге” МБ Башкарма комитеты җитәкчесе — Р.Х.Хәбибуллин;

5) Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе — И.Г.Сиражиев.

Ачык тыңлаулар башлану турында хәбәр Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (https://arsk.tatarstan.ru) 2025 елның 17 ноябрендә басылып чыкты һәм анда **түбәндәге мәгълүматлар бар иде**:

Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:

1) I өлеш. Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләрен куллану һәм күрсәтелгән кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү тәртибе;

2) II өлеш. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

3) III өлеш. Шәһәр төзелеше регламентлары;

4) шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы.

Территориаль зоналар. ЗОУИТ;

5) Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Территориаль зоналар.

- Ачык тыңлауларны үткәрү тәртибе һәм сроклары;

- Ачык тыңлауларда катнашучылар даирәсе

- Ачык тыңлаулар уздырыла торган Территория;

- Ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен (экспозицияләрен) ачу урыны һәм датасы;

- Проект экспозициясен (экспозицияләрен) үткәрү сроклары;

- Экспозицияне (экспозицияләрне) карарга мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат;

- Ачык тыңлауларда катнашучыларның проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше;

- Ачык тыңлауларда катнашучылар җыелышын (җыелышларын) үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат;

- Ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат, һәм аңа мәгълүмати материаллар;

Ачык тыңлаулар уздырылу территориясе: Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12 йорт.

Җәмәгать фикер алышуларында (ачык тыңлауларда) катнашучыларның тәкъдимнәре һәм кисәтүләре 2025 елның 24 ноябреннән 2025 елның 8 декабренә кадәр кабул ителде.

Күрсәтелгән чор дәвамында иҗтимагый фикер алышуларда (ачык тыңлауларда) катнашучылардан түбәндәге тәкъдимнәр һәм искәрмәләр керде:

| № п/п | Катнашучы турында белешмәләр (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туу датасы, яшәү (теркәлү) урыны адресы – физик затлар өчен; исеме, төп дәүләт теркәү номеры, тору урыны һәм адресы – юридик затлар өчен) | Тәкдимнең һәм (яисә) искәрмәнең эчтәлеге |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Территориядә даими яшәүче гражданнарның тәкъдимнәре һәм искәрмәләре | | |
| | Арча муниципаль районының мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм палатасы җитәкчесе — Сираьиев Ильһам Гаптельнур улы | Ж1 территориаль зонасы (индивидуаль торак төзелеше зонасы) җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре исемлегенә рөхсәт ителгән файдалану төрләрен кертергә<br>- дини файдалану (классификатор буенча код 3.7); |

| | | |
|---|---|---|
| | | - кибетләр (классификатор буенча код 4.4). |
| Башка катнашучыларның тәкъдимнәре һәм искәрмәләре | | |
| | | |

Ачык тыңлаулар башлану турында хәбәр итүне бастырып чыгару турындагы Акт, проектны карауда катнашкан гавами тыңлауларда катнашучылар исемлеге кушымтада бирелә.

Имзалар:

Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары ____________ Р.Р.Филиппова

Юридик мәсьәләләр буенча бүлек башлыгы ____________ Л.Г.Сагитова

Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы ____________ И.М.Хасанов

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы ____________ Р.Х.Хабибуллин

Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе ____________ И.Г.Сиразиев